# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегең нәтиҗәләре турында**

**25 январь, 2021 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2021 елның 23 январендә 11 сәгатьтә 00 минутта гражданнар җыенының беркетмәсе каралды :

1. Багай авыл җирлеге башлыгының 2020 елгы эш нәтиҗәләре башкарылган ошкэ омгак ясалуы, һәм 2021 елга ош исәбе куелды.
2. коммуналь чүп чар калдыкларын капчыкта җыюны гамәлгә ашыру.
3. Багай авыл җирлегендә яшәүче халыкның туганнарын түләүле шартларда җирләү, бэясе -5 мең сумга каралу .

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 73 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 73, бу 100 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 73 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Багай авыл җирлеге башлыгының 2020 елгы эш нәтиҗәләре һәм 2021 елга планлы отчетын игътибарга алырга.

3. Багай авыл җирлегендә яшәүче халыкның туганнарын түләүле шартларда җирләү, бэясе -5 мең сумга каралу .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф.Кузнецова